РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
АДАВ-ТУЛУМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АДАВ-ТОЛЫМБАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

3 сентябрь 2018 ел № 2-47

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын һәм үзара салым акчаларын куллану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын һәм үзара салым акчаларын куллану тәртибе турындагы нигезләмәгә, аны әлеге карарның кушымтасы нигезендә яңа редакциядә раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш һәм ТР, Буа районы, ТР, Буа районы, Ада-Толымбай авылы, Совет ур., 19 йорт, ТР, Буа районы, Яңавыл авылы, Яшьләр ур., 53 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге Советының 2014 елның 1 апрелендәге 1-45 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчасын җыю һәм куллану тәртибе

турындагы нигезләмә һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Адав-Толымбай авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Хөсниева

Буа муниципаль районы Адав-Толымбай
авыл җирлеге Советының
2018 елның 03 сентябрендәге
2-47 номерлы карарына
1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын һәм үзара салым акчаларын куллану тәртибе турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге (алга таба -Җирлек) территориясендә җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен халыкның өстәмә акчаларын җәлеп итү һәм куллану тәртибен җайга сала.

2.1. Гражданнар - яшәү урыны Җирлек чикләрендә урнашкан Россия Федерациясе гражданнары.

Гражданнарның үзара салым акчасы астында гражданнарның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен башкарыла торган бер тапкыр бирелә торган түләүләре аңлашыла.

Гражданнарның үзара салымы мәсьәләсе буенча җирле референдум – гамәлдәге законнар, җирлек уставы нигезендә җирлек чикләрендә яшәү урыны буенча теркәлгән Россия Федерациясе гражданнары арасында үзара салым мәсьәләсе буенча яшерен тавыш бирүдә гражданнарның гомуми тигез һәм турыдан-туры ихтыярын белдерү нигезендә үткәрелә торган референдум.

### 2. Гражданнарның үзара салым мәсьәләсе буенча референдум үткәрү турында инициативаны тәкъдим итү

2.1. Үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә.

2.2. Гражданнарның үзара салым мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән:

- җирле референдумда катнашу хокукына ия Россия Федерациясе гражданнарына;

- устав сайлауларда һәм (яки) референдумнарда катнашуны күздә тоткан, федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлгән сайлау берләшмәсенә, башка иҗтимагый берләшмәгә;

- алар тарафыннан бергәләп тәкъдим ителгән авыл җирлеге советына һәм авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә.

### 3. Җирле референдумны билгеләү, әзерләү һәм үткәрү

3.1. Җирле референдум билгеләү турындагы карар җирлек Советына җирле референдум билгеләнә торган документлар кергән көннән 30 көн эчендә җирлек Советы тарафыннан кабул ителә.

3.2. Җирле референдумны әзерләү һәм үткәрү тәртибе «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән җайга салына.

3.3. Җирле референдумны әзерләү һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслау җирлек бюджеты акчалары хисабына башкарыла.

## 4. Җирле референдум карары

4.1. Гражданнарның үзара салымы җирле референдумда кабул ителгән карар буенча җирлек территориясендә кертелә.

4.2. Референдум үзара салым буенча түләүләр күләмен һәм җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне раслый, аларны хәл итүгә җыелган акчалар тотыла. Гражданнарның үзара салымы тәртибендә түләүләр күләме, аерым категорияләрдән тыш, җирлекнең барлык гражданнары өчен абсолют зурлыкта билгеләнә.

4.3. Тавыш бирү нәтиҗәләре һәм җирле референдумда кабул ителгән карар җирлекнең мәгълүмат стендларында ТР, Буа районы, Адав-Толымбай авылы, Совет ур., 19 йорт, ТР, Буа районы, Яңавыл авылы, Яшьләр ур., 53 йорт адресы буенча урнаштыру юлы белән мәҗбүри хәбәр ителергә тиеш. Җирле референдумда кабул ителгән карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

4.4. Үзара салым билгеләү турында референдум карары җирлекнең барлык гражданнары өчен мәҗбүри булып тора.

4.5. Үзара салым акчаларын җыю тәртибе муниципаль берәмлекнең хокукый акты белән билгеләнә.

## 5. Үзара салым акчаларын куллану

5.1. Үзара салым тәртибендә җыелган һәм җирлек бюджетына кергән акчалар җирле референдумда кабул ителгән карарда каралган җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне (конкрет мәсьәлә) хәл итүгә җирлек башкарма комитеты тарафыннан тотыла.

5.2. Референдумда кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән 10 көн эчендә җирлекнең башкарма комитеты референдум карарын тормышка ашыру максатыннан чаралар планын раслый.

5.3. Хисап елында файдаланылмаган акчалар киләсе финанс елына күчә һәм референдум карары белән каралган максатларга тотыла.

5.4. Җирлек башлыгы елга бер тапкыр җирле референдумда кабул ителгән карарның үтәлеше турында җирлек халкы алдында хисап тота.

5.5. 5.4 пункты нигезендә әзерләнгән авыл җирлеге башлыгының хисаплары җирлекнең мәгълүмат стендларында ТР, Буа районы, Адав-Толымбай авылы, Совет ур., 19 йорт, ТР, Буа районы, Яңавыл авылы, Яшьләр ур., 53 йорт адресы буенча урнаштырыла.

5.6. Үзара салым акчаларын дөрес исәпләүне, тулысынча һәм үз вакытында түләүне тикшереп торуны җирлек башкарма комитеты башкара.

## 6. Әлеге Нигезләмәне бозган өчен җаваплылык

6.1. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салымы акчалары федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

6.2. Акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Контроль-хисап палатасы тарафыннан башкарыла.